**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, поселогы,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 18.05.2020 № 400

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 979 нчы номерлы "Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр билгеләү турында" карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында спорт резервын әзерләүче Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты башкара торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләрне билгеләргә:

эшләнгән чорга пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә стимуллаштыра торган ай саен өстәмә түләү, әмма аена 1 111 сумнан артык түгел;

2. Гамәлгә куючысының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү Тәртибен кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo/tatarstan/ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның
18 маендагы 400 нче номерлы карарына

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА СПОРТ РЕЗЕРВЫН ӘЗЕРЛӘҮНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ МУНИЦИПАЛЬ ФИЗКУЛЬТУРА СПОРТ ОЕШМАЛАРЫНДА ЭШЛӘҮЧЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ - ЯШЬ БЕЛГЕЧЛӘРГӘ АКЧАЛАТА ТҮЛӘҮЛӘР БИРҮ ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты башкара торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында (алга таба – оешмалар) эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләрне бирүнең тәртибен һәм шартларын билгели:

эшләнгән чорга пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә стимуллаштыра торган ай саен өстәмә түләү, әмма аена 1 111 сумнан артык түгел.

2. Оешмаларның хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында Биектау муниципаль районы бюджетына каралган акчалар исәбеннән башкарыла.

Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының төп бүлүчесе булып Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (алга таба - ФБП) тора.

3. Оешманың хезмәткәре - яшь белгече дип, 30 яшькә (кертеп) кадәрге, көндезге уку формасы буенча беренче тапкыр һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган, бакалавриат, специалитет, магистратура программалары буенча дәүләт аккредитациясенә ия булган (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү мәгариф оешмасы), һәм һөнәри белем һәм квалификация дәрәҗәсе нигезендә хезмәт шартнамәсе буенча оешмага һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча: физкультура буенча инструктор, педагог-оештыручы, педагог-психолог, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, тренер, адаптив физик культура буенча тренер-укытучы, хореограф, тренерлык процессы администраторы, адаптив физик культура буенча өлкән тренер вазыйфаларында эшкә алынган Россия гражданы таныла.

4. Ай саен түләнә торган стимуллаштыручы өстәмә түләү хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә аны эшкә урнаштыру аеннан соң килүче айның 1 числосыннан башлап билгеләнә һәм, әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфада өзлексез эшләгән очракта, билгеләнгән датадан башлап өч ел дәвамында түләнә.

Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен түләнә торган стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты” МКУсенең

“Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге” МКУсе (алга таба - Башкарма комитет бүлеге) боерыгы белән раслана.

Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен түләнә торган стимуллаштыручы өстәмә түләү түбәндәге чорларга озайтыла:

Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә яисә альтернатив гражданнар хезмәтендә чакырылыш буенча хезмәтләр;

йөклелек һәм бала табу буенча отпуск, өч яшькә җиткәнче бала карау буенча отпуск;

көндезге бүлектә аспирантурада уку.

5. Хезмәткәр - яшь белгеч әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфага башка оешмага күчкәндә, эштә 30 көннән дә артык булмаган тәнәфес рөхсәт ителә.

6. Саны яки штаты кыскаруга бәйле рәвештә хезмәткәр - яшь белгеч эштән азат ителгәндә, алга таба әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфага башка оешмага эшкә урнашканда 60 көннән дә артык булмаган тәнәфес рөхсәт ителә.

7. Ай саен түләнә торган стимуллаштыручы өстәмә түләү хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә бары тик яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

8. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен түләнә торган стимуллаштыручы өстәмә түләү әлеге хезмәткәр - яшь белгеч тарафыннан эчке берләшү шартларында гамәлгә ашырыла торган төп вазыйфасы һәм вазыйфасы буенча билгеләнә, әмма 1 ставкадан артмый.

9. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә ай саен түләнә торган стимуллаштыручы өстәмә түләү түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times \frac{H_f}{H_n},$$

монда:

D - хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме, сум;

P – айга 1 111 сум күләмендә хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү;

Hf - хезмәткәр- яшь белгеч эшләгән сәгатьләрнең фактик саны, сәгать;

Hn - спорт резервын әзерләү оешмасы хезмәткәрләренең хезмәт хакының база ставкасы өчен сәгать нормасы, сәгать.

10. Башкарма комитет бүлеге ай саен, айның 5 нче числосына кадәр, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына (алга таба - Министрлык) түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга акчалар бирү турында заявка;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча оешманың хезмәткәрләре - яшь белгечләре реестрлары.

11. Министрлык әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны алар кергән көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә карый.

Әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән тулы булмаган документлар

пакеты яисә югарыда аталган пункт таләпләренә туры килми торган документлар тапшырылган очракта, Министрлык гаризаны кире кайтара һәм кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, биш көн эчендә оешмага хәбәр итә.

Башкарма комитет бүлеге гаризаны кире кайтару турында хәбәр алган көннән әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәгән очракта кабат тапшыра..

12. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне башкару өчен оешма чыгымнарын финанс белән тәэмин итү ФБП тарафыннан күрсәтелгән максатларга субсидия бирү юлы белән башкарыла. Субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы раслаган типовой форма нигезендә Министрлык һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелгән килешү нигезендә (алга таба - Килешү) бирелә.

Килешү әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән алып 10 көн эчендә төзелә.

13. ФБП хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүне гамәлгә ашыруга субсидияләрне оешмаларның шәхси счетларына ай саен күчерә.

14. ФБП ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15 нче числосыннан соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетларының чыгымнары һәм килешүдә каралган форма һәм тәртип нигезендә башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында хисаплар тапшыра.

15. Агымдагы финанс елында оешма тарафыннан файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешләре билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиеш.

16. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны контрольдә тоту законнар нигезендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

17. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге йөзендә Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен законнар нигезендә җаваплылык тота.